| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.11.2021 Казан ш. № 257-44/тэ-2021

«Спас коммуналь челтәрләре» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга җиткерелә торган җылылык энергиясе (егәрлеге) өчен 2022 елга тарифлар билгеләү хакында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя билгеләү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Спас коммуналь челтәрләре» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (алга таба – «Спас коммуналь челтәрләре» ҖЧҖ) тарафыннан кулланучыларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) әлеге карар кушымтасына туры китереп, календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2022 елның 1 гыйнварыннан 2022 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач гамәлгә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
12.11.2021 № 257-44/тэ-2021
карарына кушымта

«Спас коммуналь челтәрләре» ҖЧҖ тарафыннан кулланучыларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) 2022 елга календарь буенча бүлгәләнгән тарифлар

| Т/с | Муниципаль берәмлек, җайга салынулы оешма атамасы, тариф төре | Ел | су | Басым астында сайланган пар | | | | Әче һәм редукцияләнгән пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2 башлап 2,5 кг/см$^2$ кадәр | 2,5 башлап 7,0 кг/ | 7,0 башлап 13,0 кг/см$^2$ кадәр | 13,0 кг/см$^2$ югары | |
| | Спас муниципаль районы | | | | | | | |
| 1 | «Спас коммуналь челтәрләре» ҖЧҖ* | | | | | | | |
| 1.1 | Кулланучылар өчен, тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгән очракта | | | | | | | |
| | бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 2050,04 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 2139,17 | - | - | - | - | - |

<*> Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге